*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 52**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Иренләшкән сузык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [ө]
   ә) [ә]
   б) [и]
   в) [э]

2. Җөмләдәге ябык иҗекләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Бер тамчыдан диңгез булмый*. (Мәкаль).
   а) 1
   ә) 2
   б) 7
   в) 8

3. *Сыек* сүзенең антонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) күп
   ә) тәбәнәк
   б) сай
   в) куе

4. Искергән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) ашханә
   ә) ошбу
   б) ноутбук
   в) тимер

5. Кушма исемне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) каен(җиләге)
   ә) тирә(як)
   б) таш(кабак)
   в) дус(иш)

6. Кимлек дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) кызыл

ә) кызылрак
б) кып-кызыл
в) кызгылт

7. Хәзерге заман хикәя фигыльне билгеләгез. **(2 балл)**
а) бара
ә) барыр
б) барачак
в) барган

8. Җәенке җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) Кояш яктырта.
ә) Кура җиләкләре өлгергән.
б) Сандугач матур сайрый.
в) Алмаз җырлый, бии.

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

[х], [һ], [ц] – _____________ саңгырау тартыклар. Татар телендә сузык авазлар калын һәм ____________ була. Башка телләр аша татар теленә кергән сүзләр _______________ сүзләр дип атала. Парлы сүзләр ________________ аша языла. Сөйләмдә катнашучы затларны белдерә торган алмашлыкларны татар телендә __________ алмашлыклары диләр.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(9 балл)**
*Летом мы всей семьёй отдыхали на даче. Рядом с хвойным лесом протекала широкая река. Я любил загорать на жёлтом песке и смотреть на маленькие волны.*

2. Мәкальне укыгыз, биремнәрне башкарыгыз.
*Кышка каршы тиен дә байлык җыя.* (Мәкаль)
2.1. Ябык иҗекләрдән генә торган сүзне языгыз. **(1 балл)**
2.2. Ясалма сүзне языгыз. **(1 балл)**
2.3. *Тиен* сүзен килешләр белән төрләндереп языгыз. **(2 балл)**
2.4. Фигыльнең заманын, зат-сан белән төрләнешен языгыз. **(3 балл)**

3. Сез мәкальне ничек аңлыйсыз? Шул хакта 8 җөмлә языгыз. **(15 балл)**